**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

# КАРАР

«23» сентябрь, 2025 ел

№ 696-п

2025 елның IV кварталына салым салынырга тиешле гражданнар кеременең һәм мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31- ТР Законы һәм «Социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законы һәм гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге мөлкәт хакының «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» коммерциячел булмаган партнерлыгының 2025 елның 5 маендагы 292 номерлы хаты белән, Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы ставкасы:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 3 478 975,50сум

1.1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 4 427 787,00 сум

1.1.3. Өч кешелек гаилә өчен - 5 692 869,00 сум

1.1.4. Дүрт кешелек гаилә өчен - 7 590 492,00 сум

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен - 9 488 115,00 сум

1.1.6. Алты кешелек гаилә өчен - 11 385 738,00сум

1.1.7. Җиде кешелек гаилә өчен - 13 283 361,00 сум

1.2. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык керем күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 37 986,72 сум

1.2.2. Ике кешелек гаилә өчен - 24 173,37 сум

1.2.3. Өч һәм аннан күбрәк кешенең гаиләсе өчен - 20 720,03 сум

2. Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 бүлекләрендә күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдалануны социаль наем шартнамәләре буенча

муниципаль торак фондын исәпкә кую һәм аларга торак урыннары бирү максатларында аз керемле дип тану өчен файдаланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында http://www.pestreci.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Р. Дәүләтханов